РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021 елның 30 июле 284№

«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 172 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2006 елның 2 маендагы "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 2006.02.05, 59 – ФЗ№), 2003 елның 12 маендагы " Татарстан Республикасы гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы, РФ Президентының 2017 елның 17 апрелендәге "Гражданнар һәм оешмалар мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләрен мониторинглау һәм анализлау турында" 171 номерлы әмере, 2006 елның 4 маендагы "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында" 34-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты Карар бирә:

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 24 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 172 номерлы карарына (2021.14.04, 109№ редак.) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 пунктның 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) әлеге Федераль законның 11 статьясында күрсәтелгән очраклардан тыш, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча язмача җавап алырга, ә әлеге Федераль законның 11 статьясындагы 5.1 өлешендә каралган очракта, аны бирү турындагы үтенеч белән мөрәҗәгать итү нигезендә, язма мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү компетенциясенә кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка адреслау турында хәбәр итәргә; »

2.Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталы”нда бастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми alkeevski.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлеге начальнигына йөкләргә.

Җитәкчесе: И.В.Юсупов.